# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 5** 06.12.2019 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Исәнсеф авыл җирлеге составына керүче Татар Бүләр торак пунктына 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Татар Бүләр торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1 Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Татар Бүләр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә. Ялгыз карт гражданнар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, I, II төркем инвалидлары өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә .

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Татар Бүләр авылында су белән тәэмин итүне ремонтлау һәм төзекләндерү өчен;
- Татар Бүләре авылы территориясендә һәйкәлләрне ремонтлау өчен;
- Татар Бүләр авылында юлларны кышкы һәм җәйге карап тотуга;
- территорияне киртәләү буенча төзелеш материаллары сатып алу өчен;

Татар Бүләр авылы мәдәният йорты Татбуляр клубы;
- Татар Бүләре авылы юлларында таш түшәлде;
- Татар Бүләр авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май, волейбол, яшьләр арасында теннис ярышлары) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- Татар Бүләр авылында Сабантуй территориясендә электр белән тәэмин итү линияләрен үткәрү өчен кабель сатып алу;
- Татар Бүләр авылы урам яктырткычлары сатып алу;
- Татар Бүләр авылы территориясендә үлән чабу һәм куаклар кисү;

Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылган: http// muslumovo.tatarstan.ru Мөслим муниципаль районы, Татар Бүләре авылы, Дуслык урамы, 5а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында да бар.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Татар Бүләр авыл җирлеге башлыгы И.А.Салихов